| | | |
|---|---|---|
| СОВЕТ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>СОВЕТЫ |

| | | |
|---|---|---|
| **РЕШЕНИЕ**<br>**17.12.2024** | Зеленодольск<br>шәһәре | **КАРАР**<br>**№ 443** |

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Советының 2021 елның 17 декабрендәге 129 номерлы карары белән расланган (Зеленодольск муниципаль районы Советының 2022 елның 24 мартындагы 148 номерлы, 2023 елның 28 декабрендәге 359 номерлы карарына кертелгән үзгәрешләр белән), Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы җирлекләре территориясендә җылылык белән тәэмин итү объектларын төзү, реконструкцияләү һәм (яисә) модернизацияләү буенча бердәм җылылык белән тәэмин итүче оешма тарафыннан йөкләмәләр үтәлешенә муниципаль контроль турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

2010 елның 27 июлендәге «Җылылык белән тәэмин итү турында» 190-ФЗ номерлы Федераль законның 23.14 статьясы, 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясындагы 1 өлешенең 4.1 пункты, 2020 елның 31 июлендәге «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 248-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Советы **карар кылды:**

1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Советының 2021 елның 17 декабрендәге 129 номерлы карары белән расланган (Зеленодольск муниципаль районы Советының 2022 елның 24 мартындагы 148 номерлы, 2023 елның 28 декабрендәге 359 номерлы карарына кертелгән үзгәрешләр белән), Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы җирлекләре территориясендә җылылык белән тәэмин итү объектларын төзү, реконструкцияләү һәм (яисә) модернизацияләү буенча бердәм җылылык белән тәэмин итүче оешма тарафыннан йөкләмәләр үтәлешенә муниципаль контроль турындагы нигезләмәгә (алга таба - Нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. «Муниципаль контрольне гамәлгә ашыру кысаларында тикшерелә торган мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторлары исемлеге» 2 нче кушымтаны, әлеге карарга 1 нче кушымта да каралганча, яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Интернет челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми (http://pravo.tatarstan.ru) порталында һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) сайтында урнаштырырга.

**Зеленодольск**
**муниципаль районы Башлыгы,**
**Совет рәисе** **М.П. Афанасьев**

Зеленодольск муниципаль районы
Советының 2024 елның 17 декабрендәге
443 номерлы карарына
1 нче кушымта

«Зеленодольск муниципаль районы
Советының 2021 елның 17 ноябрендәге
129 номерлы карарына
2 нче кушымта

**Муниципаль контрольне гамәлгә ашыру кысаларында тикшерелә торган мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторлары исемлеге**

Зеленодольск муниципаль районы җирлекләре территориясендә җылылык белән тәэмин итү объектларын төзү, реконструкцияләү һәм (яисә) модернизацияләү буенча бердәм җылылык белән тәэмин итүче оешма тарафыннан йөкләмәләрне үтәү буенча муниципаль контрольне тотканда мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторлары күрсәткечләре:

- Рәттән өч ай эчендә бер үк җылылык белән тәэмин итү объектында ике һәм аннан күбрәк авария булу;
- Рәттән өч ай эчендә җылылык белән тәэмин итүнең ышанычлылыгы, шулай ук бердәм җылылык белән тәэмин итүче оешма һәм җылылык энергиясен кулланучы арасында барлыкка килә торган каршылыклар мәсьәләләре буенча кулланучыларның ике һәм аннан күбрәк мөрәҗәгатьләре;
- Җылылык белән тәэмин итү схемасында аның өчен билгеләнгән җылылык белән тәэмин итү системасын үстерү, аның ышанычлылыгын һәм энергетик нәтиҗәлелеген арттыру өчен кирәкле җылылык белән тәэмин итү объектларын төзү, реконструкцияләү һәм (яисә) модернизацияләү чаралары исемлеген бердәм җылылык белән тәэмин итүче оешма тарафыннан үтәмәү.»